**СОВЕТ БИРЮЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422737, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.Бирюлинского з/, ул. Кольцевая, 33

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422737, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Бөреле җәнлек совхозы пос , Боҗар ур., 33

Тел./факс: +7(84365) 76-5-45, e-mail: Brl.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**11 февральде 2020 г.** **№ 127**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында” 2003 нче ел, 6 нчы октябре, 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 нче ел, 2 нче марты, 25-ФЗ номерлы, 2019 нчы ел, 16 нчы декабре 432-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә коррупциягә каршы тору турындагы законнарны камилләштерү максатыннан Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законнары, Татарстан Республикасының 2013 нче ел, 25 нче июнь 50-ЗРТ номерлы муниципаль хезмәт турындагы Кодексына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Бөреле авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2019 нчы ел, 31 нче октябрь, 126 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 нче маддәнең 1 нче бүлеген түбәндәге эчтәлекле 12 нче пункт белән тулыландырырга:

«12) җирле бюджет хисабына муниципаль хокукый актлар нигезендә өстәмә һөнәри белем алу.»;

2) 5нче маддәнең 1 нче бүлеге 11 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә мәнфәгать каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә һәм андый конфликтларны булдырмау өчен чаралар күрергә.»;

3) 6 нчы маддәдә:

а) 1 нче бүлекнең 4 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«4) “ Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законы нигезендә муниципаль хезмәткә керү һәм аны башкаруга киртә булган һәм медицина оешмасы тарафыннан расланган авыру булу”;

б) 7 нче һәм 8 нче пунктларда «район” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 нче бүлекне түбәндәгечә бәян итәргә:

«3.Гражданин муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан муниципаль оешманың вәкиллекле органы рәисе, муниципаль оешма башлыгы, җирле администрация башлыгы, суд һәм хокук саклау органнары җитәкчесе белән туганлык мөнәсәбәтләрендә торганда (әти-әни, ир-хатын, балалар, ир туганнар, кыз туганнар, шулай ук ир-хатыннарның ир туганнары, кыз туганнары, ир-хатыннарның балалары һәм балаларның ир-хатыннары) муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органына аудитор һәм рәис урынбасары итеп билгеләнә алмый, шулай ук муниципаль хезмәткәр контроль-хисап органының аудиторын һәм рәис урынбасарын алыштыра алмый »;

4) 7 нче маддәдә:

а) 1 нче бүлек в) пунктчасында “район” сүзен төшереп калдырырга;

б) 1 нче бүлекнең 2 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

2) коммерцияле һәм коммерциясез оешмалар идарәсендә түбәндәге очраклардан кала катнашырга:

а) түләсез нигездә сәяси партия, профессиональ союз органы белән идарә итүдә, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берлекнең сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка җәмәгать оешмаларының, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездларында (конференцияләре) яки гомуми җыелышларында катнашу ;

б) Татарстан Республикасы законы билгеләгән тәртип буенча алынган эш бирүче вәкиле рөхсәте белән түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси партия, профессиональ союз органы белән идарә итүдә, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берлекнең сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка җәмәгать оешмаларының, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездларында (конференцияләре) яки гомуми җыелышларында катнашудан тыш);

в) түләүсез нигездә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советында, башка муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау;

г) түләүсез нигездә, оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыруның тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр белән (устав капиталы өлешләре белән) идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларга туры китерелгән, гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

в) 2.1 пункты белән алдагы эчтәлектә тулыландырырга:

«2.1) шәхси эшмәкәрлек белән шәхсән яки ышанычлы затлар аркылы шөгыльләнергә;»;

г) 1 нче бүлекнең 3, 5, 8 нче пунктларында «районы» сүзен төшереп калдырырга;

5) 5) 8 нче маддәне түбәндәгечә бәян итәргә:

8 нче маддә. Муниципаль хезмәт вазыйфаларына квалификацион таләпләр

«1.Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше, белем һәм осталык буенча эш стажына, шулай ук эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булган очракта - белгечлек, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләренә туры килүе таләп ителә;

2.Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә түбәндәге квалификацион таләпләр куела:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә:

билгеле юнәлеш эшчәнлеге буенча вазыйфаларның иң югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу; югары белем яисә урта һөнәри белем булу – билгеле юнәлеш эшчәнлеге буенча өлкән һәм кече төркем вазыйфалары өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең иң югары вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәт стажы ике елдан ким булмаган яки белгечлек, юнәлеш буенча дүрт елдан ким булмаган эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәт стажы бер елдан ким булмаган яки белгечлек, юнәлеш буенча ике елдан ким булмаган эш стажы;.»;

6) 10 нчы маддәдә:

а) 3 нче бүлекнең 1 нче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) 5 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. 2 һәм 3 нче класслы муниципаль хезмәт сәркатибе һәм референтына класс чиннарында булуның минималь вакыты – бер ел, 2 һәм 3 нче класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе һәм муниципаль киңәшче – ике ел, 2 һәм 3нче класслы хакыйкый муниципаль киңәшче – бер ел тәшкил итә. Сәркатиб, референт, муниципаль хезмәт киңәшчесе, муниципаль киңәшче һәм хакыйкый муниципаль киңәшчесенең 1 нче класс чиннарында булу вакыты билгеләнми. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрнең класс чиннарында аларны югары төркем муниципаль хезмәтнең вазыйфаларына күчергәндә арттыру мөмкин.»;

7) 11 нче маддәне төшереп калдырырга:

8) 13 нче маддәдә:

а) 1 нче бүлектәге “ел саен” сүзен төшереп калдырырга;

б) 9 нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Банк, салым яки башка закон белән саклана торган серне тәшкил итүче белешмәләрне тапшыру турында запрослар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын тиешле исемлеккә кертелгән гражданнарга карата оператив-эзләү чараларын үткәрү турында хокук саклау органнарына запрослары, әлеге вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр, мондый гражданнарның ире (ир белән хатынның) һәм балигъ булмаган балаларының муниципаль хезмәткәрләре муниципаль органнар мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия

Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган тәртиптә җибәрелә.»;

9) 14 нче маддәдә:

а) 3 нче бүлекнең 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета »;

б) 3 нче бүлекнең 6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) мәҗбүри пенсия иминиятенең  иминият таныклыгы, әгәр дә хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагыннан кала»;

в) 7 нче бүлекнене төшереп калдырырга;

10) 15 нче маддәнең 2 нче бүлеге 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә таләп ителгән һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше, белем һәм осталык буенча эш стажына квалификацион таләпләр – эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булган очракта -  белгечлек, әзерлек юнәлеше квалификацион таләпләренә туры килүе таләп ителә;»;

11) 17 нче маддәнең 1 нче бүлек 7 нче пунктында “социаль” сүзен төшереп калдырырга;

12) 18 нче маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 нче маддә.Муниципаль хезмәт стажы

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексының 29 нчы маддәсендә билгеләнгән вазифаларда даими (штат) рәвештә  эш (алмаштыру) еллары муниципаль хезмәт стажына (гомуми озынлыгына) кертелә»

13) 19 нчы маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 нчы маддә. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү һәм билгеләү тәртибе.

Муниципаль хезмәт стажын исәпләү РОссия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары билгеләгән тәртиптә башкарыла.»;

14) 21 нче маддәне төшереп калдырырга;

15) 22 нче маддәнең 1 нче бүлеге 4 һәм 6 нчы пунктларындагы “район” сүзен төшереп калдырырга;

16) 23 нче маддәдә:

а) 3 нче бүлекне түбәндәгечә бәян итәргә:

«3. Әлеге Федераль закон белән каралган очраклардан тыш, дисциплинар җәзалар куллану һәм кире алу тәртибе хезмәт турындагы законнар белән билгеләнә.»;

б) 4 нче бүлектә әлеге «Федераль закон белән» сүзләрен төшереп калдырырга»;

в) 9 нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. 2007 нче ел, 2 нче марты 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законының 14.1, 15 һәм 27 нче маддәләрендә каралган җәзалар, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупцион хокук бозуы турында мәгълүмат алынган көннән алты айдан соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә яраксыз чорын, аның ялда вакытын санамыйча, һәм аның тарафыннан коррупцион хокук бозган көненнән өч елдан да соңга калмыйча кулланылалар. Күрсәтелгән срокларга җинаять эшен тикшерү вакыты кертелми.».

17) 24 нче маддәне төшереп калдырырга;

18) 25 нче маддәдә:

а) 4 нче бүлектә җәяләр эченә алынган (дәвамлылыгы 10 календарь көннән артмаган) сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 8 һәм 9 нчы бүлекләрне төшереп калдырырга;

19) 27 нче маддәдә:

а) “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” сүзләрен “Иминият пенсияләре” сүзләре белән алыштырырга;

б) 4 нче бүлектә «дәүләт яки муниципаль” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 7 нче бүлекне «бюджет» сүзе белән тулыландырырга;

г) 8 нче бүлекне төшереп калдырырга

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Совет рәисе,
Авылҗирлегебашлыгы Т.Х.Багаутдинов